СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 124 от 21.02.2022

на № _________от ______________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү
турында

2014 елның 19 декабрендә кабул ителгән 281 номерлы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставын «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Россия Федерациясе Законының 44 статьясына, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Саба муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставын яңа редакциядә кабул итү турында» 2014 елның 19 декабрендәге 281 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының https://saby.tatarstan.ru/ рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Саба муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы А.И. Миңнекаевка әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башлыгы урынбасары Р.Р. Закирҗановка йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Советының
2022 елның 21 февралендәге
124 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

**1.** 6 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 13.1 һәм 13.2 пунктчалары өстәргә:

40) җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан кишәрлек урманчылыклары составында төзелә торган урманчылыкларны төзү, бетерү, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында, шулай ук җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын эшләүне һәм раслауны гамәлгә ашыру турында карарлар кабул итү;

41) җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман корылышы чараларын гамәлгә ашыру;

**2.** 6 статьяның 1 пунктының 5 пунктчасында «җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышы өчен» сүзләрен «автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында» сүзләренә алмаштырырга;

**3.** 6 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9.1 пунктча өстәргә:

«9.1) шәһәр һәм авыл торак пунктларыннан читтәге муниципаль районнар чикләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү;»;

**4.** 6 статьяның 1 пунктындагы 27 пунктчасында «файдалану һәм саклау» сүзләрен «саклау һәм файдалану» сүзләренә алмаштырырга;

**5.** 6 статьяның 1 пунктындагы 35 пунктчасында «, ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион уздыру» сүзләрен төшереп калдырырга;

**6.** 6 статьяның 1 пунктындагы 39 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«39) комплекслы кадастр эшләрен башкаруны федераль закон нигезендә оештыру һәм территориянең карта-планын раслау.»;

**7.** 6 статьяның 2 пунктындагы 2 пунктчасында «җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышы өчен» сүзләрен «автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында» сүзләренә алмаштырырга;

**8.** 6 статьяның 2 пунктындагы 17 пунктчасында «файдалану һәм саклау» сүзләрен «саклау һәм файдалану» сүзләренә алмаштырырга;

**9.** 6 статьяның 2 пунктындагы 23 пунктчасында «, ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион уздыру» сүзләрен төшереп калдырырга;

**10.** 6 статьяның 2 өлешендәге 25 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25) комплекслы кадастр эшләрен башкаруда федераль закон нигезендә катнашу.»;

**11.** 6 статьяның 2 пунктының 26 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

26) бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча йөкләмәләрнең үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

**12.** 12 статьяның 4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) инициатив проектлар;»;

**13.** 16 статьяны яңа редакциядә бәян итәргә:

«16 статья. Инициатив проектлар.

1. Район халкы яисә аның өлеше өчен өстенлекле әһәмияткә ия чараларны гамәлгә ашыру максатларында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне яисә хәл итү хокукы җирле үзидарә органнарына бирелгән башка мәсьәләләрне хәл итү буенчаБашкарма комитетка инициатив проект кертелергә мөмкин. Инициатив проектлар гамәлгә ашырыла ала торган район территориясенең бер өлешен билгеләү тәртибе район Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

9. Инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу, карау шулай ук аларны конкурс нигезендә сайлап алу тәртибе район Советы тарафыннан билгеләнә.

**14.** 6 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 27 пунктча өстәргә:

«27) җирлек территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез мөлкәтнең хокук ияләрен ачыклау буенча карарлар кабул итү һәм чаралар уздыру, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен әлеге күчемсез мөлкәт объектларының хокукка ия булучылары турында белешмәләр җибәрү.»;

**15.** 7 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 16 пунктча өстәргә:

«16) алкоголь, наркотик яисә башка токсик исереклек халәтендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.»;

**16.** 7 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 17 пункт өстәргә:

«17) муниципаль янгын сагын булдыру.»;

**17.** 19 статьяның 4 пунктында «, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезләмәләрен исәпкә алып, әлеге Устав һәм (яисә) норматив хокукый акт белән билгеләнә торган оештыру һәм үткәрү тәртибе» сүзләрен «шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

**18.** 19 статьяның 6 пунктында «гамәлдәге законнар» сүзләреннән соң «шул исәптән аны җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында яисә җирле үзидарә органының үз эшчәнлеге турында мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру мөмкинлеге булмаса, «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, районның рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, муниципаль берәмлек кешеләренең фикер алышуга чыгарылган муниципаль хокукый акт проекты буенча, шул исәптән рәсми сайт ярдәмендә, үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен тапшыру мөмкинлеге» сүзләрен өстәргә.

**19.** 19 статьяның 6 пунктына түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән материалларны һәм мәгълүматны урнаштыру, район кешеләренең муниципаль хокукый акт проекты буенча үз кисәтүләрен һәм тәкъдимнәрен бирү мөмкинлеген тәэмин итү өчен, шулай ук мондый максатлар өчен рәсми сайтны мәҗбүри файдалану таләпләрен үтәп, район халкының гавами тыңлауларда катнашуы өчен «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы файдаланылырга мөмкин, әлеге статьяның максатлары өчен файдалану тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.»;

**20.** 28 статьяның 7 пунктының 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) Россия Федерациясе гражданлыгы йә чит ил гражданлыгы - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылу, аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы,чит дәүләт

гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәү төре булу яки, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясе гражданының яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документ;";

**21.** 41 статьяның 1 пунктының 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) Россия Федерациясе гражданлыгы йә чит ил гражданлыгы - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылу, аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы,чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәү төре булу яки, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясе гражданының яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документ;";

**22.** 45 статьяның 1 пунктындагы 3 пунктчасының җиденче абзацында «файдалану һәм саклау» сүзләрен «саклау һәм файдалану» сүзләренә алмаштырырга;

**23.** 45 статьяның 1 пунктындагы 4 пунктчасының икенче абзацында «җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышы өчен» сүзләрен «автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында» сүзләренә алмаштырырга;

**24.** 45 статьяның 3 пунктының тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль контроль төрләрен оештыру һәм гамәлгә ашыру «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына.»;

**25.** 46 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6. Район Башлыгына язма рәвештә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы -Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданлыгын туктату турында хәбәр итәргә тиеш, аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы, яки чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) сатып алу яки яшәү рәвеше алу яки Россия Федерациясе гражданының яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алу, бу турыда билгеле булган көнне, әмма Россия Федерациясе гражданлыгы яки чит ил гражданлыгы туктатылган яисә чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) алу яисә әлеге пунктта каралган яшәү рәвеше яисә башка документ алу көненнән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча.

**26.** 50 статьяның 1 пунктының 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) Россия Федерациясе гражданлыгы йә чит ил гражданлыгы - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылу, аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы,чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәү төре булу яки, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясе гражданының яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документ;";

**27.** 70 статьяның 3 пунктында «эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен бурычлар» сүзләрен «эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары

өчен мәҗбүри таләпләр, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен бурычлар» сүзләренә алмаштырырга;

**28.** 70 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«3) гадәттән тыш хәлләр режимы гамәлдә булган чорда табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында эшләнгән норматив хокукый актлар проектлары.»;

**29.** 70 статьяның 4 пунктында «эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен бурычлар» сүзләрен «эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен мәҗбүри таләпләр, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен бурычлар» сүзләренә алмаштырырга;

**30.** 70 статьяның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«3) гадәттән тыш хәлләр режимы гамәлдә булган чорда табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында эшләнгән норматив хокукый актлар проектлары.»;

**31.** 70 статьяның 5 пунктында «инвестиция» сүзләрен «башка икътисадый» сүзләренә алмаштырырга;

**32.** 70 статьяны түбәндәге эчтәлекле 6 пункт белән тулыландырырга:

«6. Эшмәкәрлек һәм башка икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыруга һәм аларның үтәлешен бәяләү муниципаль контроль кысаларында гамәлгә ашыруга, административ җаваплылыкка тартуга, лицензияләр һәм башка рөхсәтләр, аккредитация, бәяләүнең һәм экспертизаның башка рәвешләрен бирүгә бәйле муниципаль норматив хокукый актларда булган мәҗбүри таләпләрне куллануны билгеләү һәм бәяләү тәртибе (алга таба - мәҗбүри таләпләр) 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә мәҗбүри таләпләр турында» 247-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне куллану принципларын исәпкә алып муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнә».

**33.** 89 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацында «аны» сүзен төшереп калдырырга, «Район уставы, муниципаль хокукый акт турында белешмәләрне «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 6 өлешендә каралган Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре уставларының дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү хакында» сүзләрен өстәргә.